*УДК 908 (929)*

# Казан арты базарлары-ярминкәләре тарихыннан (XIX йөз уртасы – XX гасыр башы)

***Х.З. Бәһавәтдинова***
*ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*

Мәкаләдә Казан артында урнашкан авылларда революциягә кадәр эшләгән базарлар һәм ярминкәләрнең тарихы бәян ителә. Казан һәм Чар (Царевококшайск) өязләренең татар һәм рус авылларында базарлар, ярминкәләр ачу тәртибе конкрет авыллар мисалында күрсәтелә. Земство эшчәнлеге, авыл кешеләре тормышында сәүдәнең тоткан роле анализлана. Иң зур табыш алган эре сәүдәгәрләрнең исемнәре, аларның ярдәмчеләре (приказчиклар) турында кыскача белешмә бирелә. Тикшерү нәтиҗәсендә иң зур товар әйләнеше Арча һәм Олы Әтнә базарларында, иң түбәне – Рус Алаты һәм Олы Карагуҗа авылларында булганлыгы ачыкланды.

*Ачкыч сүзләр*: базар, ярминкә, Казан арты, товар әйләнеше, сәүдәгәрләр, приказчиклар.

*Бер заман бардым Печән базарына,*
*Шунда мин таптым азык язарыма...*
*Иртә берлән кайнамакта бу базар*
*Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.*
*Г. Тукай*
*(«Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш»)*

XIX йөз – XX гасыр башларында авыл халкының социаль-икътисади тормышында базар һәм ярминкәләрнең роле зур булган. Җирле халыкка сәүдә итү өчен иң уңайлы һәм арзанлы ысул булып базарлар хезмәт иткән, чөнки крестьяннар үзләренең товарларын иң әүвәл базарларда саткан.

XIX йөз урталары – XX гасыр башында Казан артында – Арча, Рус Алаты, Балтач, Дөбъяз, Иске Ашыт, Иске Мәңгәр, Кышлау, Күлле Киме, Мәмдәл, Олы Карагуҗа, Олы Әтнә, Сарай-Чокырча, Суыксу (Студеный Ключ), Түбән Оры (Байлар Орысы), Хәтнә, Чыпчык һ.б. авылларда – базарлар эшләгән.

Товарның бүленеше төрле булуы базарларның урнашу географиясенә һәм анда яшәүчеләрнең милләтләренә дә бәйле булган. Мәсәлән, Казан губернасының төньяк өязләрендә – урман чималлары, көньякта – икмәк белән сәүдә иткәннәр. Татарлар яшәгән урыннарда кызыл товар (кызыл мал, ягъни мануфактура товары, тукымалар. – *Х.Б.*), татлы тәмләткечләр һәм көнкүреш өчен кирәкле вак-төяк товарлар белән сату итү киң таралган.

Шулай ук ел фасылы да базарларга йогынты ясаган. Кыш көне, бигрәк тә Раштуа һәм Масленица алдыннан, сәүдә яхшы барган. Көз көне һәм кышын – бал, май, тире, күн, балык һәм ит товарлары сатыла. Ә февраль аеннан соң бу товарларны җитештерү әкренләп кими бара. Алар урынына дегет, агач эшләнмәләре, авыл хуҗалыгы кирәк яраклары һәм башка товарлар белән алыштырыла.

Базар вак сәүдәгәрләрдән башка гына яши алмый. Алар төрле товарлар (икмәк, күн, азык-төлек һ.б.) сатып алалар һәм зур булмаган партияләр белән гурт сәүдәгәрләренә (шактый күп кешедән торган төркем. – *Х.Б.)* саталар. Зур базарлар булган авылларда даими рәвештә махсус базар бинаалары – тактадан яки читәннән эшләнгән кибетләр урнашкан.

***Казан һәм Чар өязендәге базарлар эшчәнлеге. 1862 ел*** [3, с.29, 50–51]**.**

| **Атнаның кайсы көнендә** | **Торак урынының исеме** | **Товарларның төрләре** | **Бер еллык товар әйләнеше** |
|---|---|---|---|
| Ял көне | Арча шәһәре | икмәк, азык-төлек, утын, балчыктан һәм агачтан ясалган савыт-саба һәм кызыл товар. | 7000 сум |
| “ – “ | Рус Алаты | он, ярма, солы, ит, балык, тоз, утын, савыт-саба һәм ситсы | 1300 сум |
| Шимбә | Олы Әтнә | ефәк, йон һәм кәгазь эшләнмәләре, утын, балчыктан һәм агачтан ясалган савыт-саба, төрле икмәк, тоз һәм ит | 6700 сум |
| Сишәмбе | Хәтнә | крестьян эшләнмәләре, балчыктан һәм агачтан ясалган савыт-саба, кызыл товар, төрле төрдәге икмәк һәм ашамлыклар | 2000 сум |
| Чәршәмбе | Балтач | ситсы, агачтан ясалган савыт-саба, утын, икмәк, ит, балык, тоз һәм тәмәке | 4000 сум |
| “ – “ | Суыксу | он, ит, савыт-саба, крестьян эшләнмәләре, утын һәм кызыл товар | 3000 сум |
| “ – “ | Түбән Оры (Байлар Орысы) | ашамлыклар, крестьян эшләнмәләре, вак товарлар, агач һәм балчыктан эшләнгән савыт-сабалар | 200 сум көмеш |
| Пәнҗешәмбе | Иске Ашыт | икмәк, крестьян товарлары, тоз, балчыктан һәм агачтан ясалган савыт-саба | 3000 сум |
| “ – “ | Олы Карагуҗа | азык-төлек, икмәк һәм крестьян эшләнмәләре | 1000 сум |

Таблицадан күренгәнчә, иң зур товар әйләнеше Арча һәм Олы Әтнә базарларында, иң түбәне – Рус Алаты һәм Олы Карагуҗа авылларында булган.

Елдан-ел халыкның икътисади көнкүрешен яхшырту йөзеннән зур авылларда базарлар, ярминкәләр ачылып торган. Авыл халкы үтенеч белән өяз земство идарәсенә мөрәҗәгать иткән, карар Казан губерна земствосы җыелышында расланган.

1866 елдан башлап Балтач авылында елга ике мәртәбә (24 июнь – 24 июль, 17–26 ноябрь көннәрендә) ярминкә уздырыла башлый. Барлыгы 52 лавканы арендалаудан 28 сум табыш алынган. Олаудан сатучылар аренда өчен түләүдән азат ителгәннәр. Ярминкәдәге товарлар күп төрле: бодай, солы, арпа ярмасы, ит, хайванның эч мае, тире әйберләре, крестьян тукымасы, киндер, фарфор һәм агачтан ясалган савыт-саба, чәй, шикәр сатылган [17, 50–53 кгз.].

Чыпчык авылында һәр елны, Троица бәйрәмендә (ял көне) торжок уздыру гадәткә кергән. Торжок борынгы заманнардан бирле уздырыла, кайсы елдан башланганын хәтерләүчеләр юк [17, 91–92 кгз.; 18]. Сәүдә иртәнге 5 тә башланып көндезге 12 гә кадәр дәвам итә. Мисал өчен, 1867 елда, барлыгы 740 сумга мануфактура, галантерия, төрле вак-төяк товарлар, крестьяннар эшләнмәләре сатылган. Шулай да, узган еллар белән чагыштырганда, икмәк уңышы начар булу һәм товарларның бәяләре югары булу нәтиҗәсендә, җирле сәнәгатьнең үсеше кимегән.

Шул ук 1867 елда Кавал волосте Мәмдәл авылында да (сишәмбе көнне) 14 лавкадан торган базар эшли башлый. Авыл халкы үзләре җитештергән икмәк, ит, балык, май һәм күн әйберләрен 390 сумлык сатканнар. Читтән 19800 сумлык товар китерелгән: агач әйберләре, утын, балчыктан ясалган савыт-саба, кызыл товар, чәй, шикәр [17, 17–18 кгз.].

1871 елның 26 октябрендә Казан өязе Чыпчык авылында (чәршәмбе) базар ачыла. Шулай ук Дөбъяз, Александровка, Олы Көек, Шыгале, Апаз авылларында да базарлар эшли башлый [18, 1–36 кгз.]. Чар өязенең Түбән Оры (чәршәмбе) һәм Кышлау (сишәмбе) исемле татар авылларында базарлар эшли. Түбән Оры авылында үз җирлекләреннән 8 кеше, ә Кышлауда 15 кеше сату итә [14, 253–257 кгз.].

1878–1879 елларда җирле халык Арча шәһәр думасыннан, елына ике тапкыр (6 гыйнвардан 13 гыйнварга кадәр һәм Троицаның беренче көненнән башлап бер атна дәвамында) ярминкә уздыру мәсьәләсен хәл итүне сорап гариза яза.

Әйтергә кирәк, управа башта игътибар белән тикшерә: 1) якын тирәдә башка ярминкәләр яки сату-алу урыннары юкмы, булса нинди товарлар белән сәүдә итәләр; 2) Арчаның үзендә нинди базарлар бар, алардагы сәүдә әйләнеше ничек тора; 3) бу ярминкәгә кайдан һәм нинди күләмдә товарлар китерелергә мөмкин?

Мәгълүматны Казан өязенең управа әгъзасы И.И. Иванов әзерли. Ул «Арча шәһәре Хәтнә базарыннан – 25, Александровкадан – 18, Иске Мәңгәрдән – 25, Чыпчыктан – 28 чакрым ераклыкта урнашкан. Чыпчык

авылында ел саен Троица бәйрәмендә зур әһәмияткә ия булмаган торжок уза. Арчаның үзендә дүшәмбе базарында 2000–3000 гә кадәр кеше җыела, товар әйләнеше 5000–8000 гә кадәр җитә. Яңа оештырыла торган ярминкәдә Минзәлә ярминкәсеннән кайтучылар (юл өсте), җирле һәм Казан сәүдәгәрләре сату итәчәкләр. Җирле икътисади шартларга килгәндә исә, Арча шәһәр халкының сукалау җирләре, хезмәт хаклары һәм башка кәсепләре булмаганда, ярминкә ачылу матди яктан һичшиксез файда китерәчәк, атап әйткәндә: шәһәр җәмәгатьчелегенә керем чыганагы, ә халыкка үз товарларын һәм әйберләрен сату һәм хәтта читтән килгән сәүдәгәрләргә вакытлыча фатир биреп тору да керем чыганагы булачак» дигән нәтиҗәгә килә [15, 7–8 кгз.].

Шулай ук, базарлы авылларның күбесе сәүдәне җанландыру уе белән ярминкәләр ачарга омтыла. Мәсәлән, 1900 елның 9 июнь көнендә Алат авыл җәмгыяте мондый карарга килә: «...һәр елның 6 декабреннән башлап бер атна дәвамында безнең авылда ярминкә ачарга. Әгәр ярминкәнең берәр көне базар көненә туры килсә (ягъни дүшәмбе көн), кибеттән кергән керем базар мәйданын арендага алучыга бирелергә тиеш, ә калган көннәрдәге табыш безнең файдага. Ярминкәдән кергән керемне җыю өчен авыл старостасы күзәтүе астында ышанычлы кешеләр сайланачак; өстәвенә, ярминкәгә барлык әзерлек йөзеннән, ягъни үлчәү, кибетләр, башка кирәк-яраклар да булдырылачак» [19, 3 кгз.].

1897 елда Урыс Үртәме авылы (хәзерге вакытта Марий Эл Республикасына керә. – *Х.Б.*) җәмгыяте земство хастаханәсе төзү теләген белдерә һәм шул уңайдан Күлле Киме авылындагы базарны үзләренә күчерүне сорый. Керемнең яртысын чиркәү файдасына кертергә теләүләрен дә искәртәләр. 1897 елгы халык санын исәпкә алу (перепись) вакытында, Күлле Киме авылы җәмгыяте хастаханә төзергә урын бирүгә каршы чыккан була. Урыс Үртәме җәмгыяте хәзер шул вакыйгадан файдаланып, үз авылларында хастаханә һәм базар ачмакчы булалар. Җан исәбен алу беткәч, Күлле Киме авылы халкы хастаханә төзергә җир бүлеп бирергә ризалаша. Өяз земство управасыннан «Күлле Киме авылындагы базар 1869 елдан, ягъни 28 ел эшли. Авылда кибетләре белән уңайлы сәүдә мәйданы бар, ул елдан-ел үсә бара. Бу базарга йөрүче татарлар өчен авыл кешеләре үз йортларында махсус калач сату, чәй эчү һәм харчевнялар булдырганнар. Базар Рус Үртәменә күчсә, татарлар өчен әһәмиятен югалтачак» [16, 88–89 кгз.] дигән җавап алына.

Шул ук елны Кармыш волосте Сарай-Чокырча авыл җәмгыяте чираттагы өяз земство җыелышында якшәмбе яки шимбә көннәрендә эшләүче базар ачу мәсьәләсен карауны сорап управага кабаттан мөрәҗәгать итәләр. Базар ачу өчен уңайлы шартлар булуны, шул исәптән Мамадыш сәүдә тракты аша товар төялгән бик күп олаулар узуны сәбәп итеп куялар. Шулай ук сәүдәгәрләр авылга ял итәргә еш туктыйлар. Сарай-Чокырча авылы белән янәшәдә, һәрберсе 100 йорттан ким булмаган бик күп авыллар урнашуы да шарт итеп күрсәтелә. Арча шәһәре яисә Мамадыш, Лаеш өязләрендәге базарлар Чокырчадан 25 яки 30 чакрым ераклыкта

урнашкан һәм базар бинасына тиешле мәйданны авылның үзендә, яки почта тракты янындагы 2 дисәтинә буш җир мәйданын бирергә мөмкин икән. Үтенеч, 146 нчы маддә нигезендә, 1897 елның 14 октябрендә узган өяз земство җыелышында уңай хәл ителә [16, 95–95 кгз.].

Товар әйләнеше дә төрлечә: Арча базарында 50 сумнан 16000 сумга кадәр, Олы Әтнәдә 50 сумнан 7000 сумга кадәр, Апазда 200 сумнан 3650 сумга кадәр, Чыпчыкта 150 сумнан 3000 сумга кадәр, Рус Алатында 80 сумнан 2000 сумга кадәр, Иске Ашытта 50 сумнан 1600 сумга кадәр тәшкил итә [8; 9; 10; 11; 12; 13]. Күрсәтелгән саннар төгәл дип әйтә алмыйбыз, кайбер сәүдәгәрләр табышларын дөрес итеп күрсәтмәгән очраклар да булган.

1902 елда Арча базарында иң зур товар әйләнеше 2 нче гильдия Арча сәүдәгәрләре Сокунов Михаил Федоровичта (16000), Щелкин Николай Прокофьевичта (11000), Гайнулла улы Гатауллада (7000) булган. Аларның һәрберсе 2 шәр склад тоткан. Шулай ук, Гайнулла уллары Гатаулла һәм Төхфәтулла Иске Ашыт авылында ике таш кибет тотканнары билгеле. Гатаулланың даими ярдәмчеләре (приказчик) Яңа Аты (хәзерге Югары Аты авылы. – *Х.Б.*) авылыннан Мөхәммәтгани Әюп улы Сабитов, Иске Ашыттан Вәлиулла Фәтхуллин, Олы Әтнәдән Шакир Закировлар булган. Төхфәтуллага уллары Фәйзулла һәм Габдуллаҗан булышкан. Бүгенге көндә Иске Ашытта таштан салынган кибет бинасының стеналары сакланган [1, с.88].

Шулай ук, Олы Әтнә базарында сәүдә итүче Байчура (хәзерге Мәмсә авылы. – *Х.Б.*) крестьяны Мөхәммәтгали Сәфәргалиевнең товар әйләнеше 7000 сум тәшкил итә. Ул үзенең приказчигы Шиңәр Кенәр (хәзерге Иске Кенәр авылы. – *Х.Б.*) авылыннан Шәрифҗан Сабирҗанов белән Иске Ашыт, Иске Мәңгәр базарларында да сату иткән һәм үзенең туган авылында кибет тоткан.

Апаз базарында иң күп товар әйләнеше Козьмодемьянск мещаны Иван Ефимов Пендюковта – 3650 сум, Чыпчыкта – Олы Әтнә авылы крестьяны Әхмәтгали Мәхмүтовныкы – 3000, Алат базарында – Кече Алат авылы крестьяны Петр Никифоров Карасевта һәм Олы Әтнәдән Сафа Әхмәдулла улы Мәхмүтовта (ярдәмчесе Габделвәли Әхмәдуллин) – 2000 шәр сум тәшкил иткән.

XX гасыр башында Казан сәүдәгәре Мөхәммәтвафа Гайнулла улы Гайфулла Гайнуллин ярдәме белән (Ташкич авылынан) Алат базарында сату иткән. Даими сату урыны Ташсу авылында булган, ярдәмчегә елга 200 сум акча түләгән.

Мөхәммәтвафа Гайнуллин – күренекле җәмәгать эшлеклесе, меценат, 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре Битаман-Ювас (хәзерге Ювас авылы. – *Х.Б.*) авылында туган. Печән базарында өч кибете булып, мануфактура товарлары белән беррәттән тимер-томыр белән дә сәүдә иткән. Казан шәһәр Думасы гласные, «Казан шәһәренең мескен мөселманнарына пособие җәмгыяте» идарәсе әгъзасы, 1 нче рус-татар училищесы попечителе булган. Казан өязенең Суыксу авылы мәчетен төзергә акчалата ярдәм иткән. Бүгенге көндә Яңа бистә татар зиратында кабере сакланган [2, с.97].

Сәүдәгәрләр приказчиклар ялласа, сату-алу әйләнешенә һәм сәүдә мәйданының күләменә карап, дүрт сыйныфның берсе буенча приказчик таныклыгын сатып алырга тиеш булганнар. Һәрбер эшкуар товар әйләнешен күрсәтә торган журнал алып барырга бурычлы. Күбесе бу журналны алып бармаган. Шуңа күрә тикшерүләр нәтиҗәсендә хуҗалар штраф түләргә мәҗбүр булганнар. Сәүдә күзәтчелеген земство полициясе башкарган. Хуҗа ярдәмчегә хезмәт хакы түләгән, күп очракта фатир һәм ашау белән тәэмин иткән. Кайбер сәүдәгәрләр үз туганнарын: энеләрен яки улларын яллаганнар. Азрак акча туплагач, үз кибетләрен ачып җибәрүче приказчиклар да булган.

1902–1915 еллар эчендә сәүдә итүчеләрнең милли составын чагыштырып карасак: Арча базарында 44% – татарлар, 56% – руслар, Иске Ашытта 86% – 14%, Олы Әтнәдә 56,8% – 43,2%, Апазда 83,3% – 16,7%, Алатта 64,9% – 35,1%, Чыпчыкта 30,8% – 69,2%ны тәшкил итә. Шулай итеп, татарлар Иске Ашыт, Апаз, Алат, Олы Әтнә, ә руслар исә – Чыпчык һәм Арча базарларында өстенлек иткәннәр. Руслар арасында күбрәк сәүдәгәр, мещан, ә татарларда – крестьян, сәүдәгәр һәм хәрби катламнар очрый [9, 152–206 кгз.].

Шулай ук базарларның роле татар авылларында этноконфессиональ составның катлаулануына да китерә. Капитализм чорына аяк басу, натураль хуҗалыктан товар-акча мөнәсәбәтләренә күчү, хезмәт мобильлегенең үсүе татар авыл җәмәгатьчелегенең йомыклыгын җимерүгә һәм Урта Идел буеның башка халыклары белән социомәдәни коммуникацияләрне арттыруга китерә. Эре сәүдә һәм сәнәгать үзәкләре булган татар авылларында бу тенденцияләр аеруча ачык чагыла. Әйтик, 1909 елда Иске Ашытта 25 рус кешесе яшәгән [7, 14–15 кгз.]. Аларның күбесе сәүдә өлкәсендә хезмәт иткән яки Ашыт базары инфраструктурасын тәэмин иткән, сәүдә кибетләрен тоткан.

Авылларда уздырыла торган бәйрәмнәрнең дә сәүдә эшенә йогынтысы булган. Казан арты татар авылларында борынгы заманнардан ук язгы кыр эшләре беткәч җыеннар уза торган була. Бәйрәм вакытында тирәюньнән сәүдәгәрләр һәм сатып алучылар җыела. Нәкъ менә җыен вакытында эшлекле элемтәләр барлыкка килгән дә инде, кайберләре хәтта туганлык мөнәсәбәтләренә әверелгән [5, с.23].

Базарлар соңгы яңалыклар алмашу урынын да, төрле формадагы игъланнар җиткерү ролен дә башкарганнар. Мисал өчен, Әтнә волосте идарәсе Олы Әтнә базарына 1870 елның 21 декабрендә узачак торглар турында игълан (Атамыш авылы крестьяннары сатып алынган мөлкәттән налоглар түләмәгән) язып куюны сорый [20, 85 кгз.].

Базарлар эшчәнлеге татар халкы тормышында тискәре күренешләр дә китереп чыгарган. Крестьян хуҗалыклары өчен чын афәт булып терлек эпидемияләре булган. 1884 елда Олы Әтнә авылында чумага каршы чыккан кагыйдәнең 23 нче маддәсе нигезендә ит, тире һәм мал белән сәүдә итү базарын авыл читенә күчерәләр. Ләкин 1896 елда авыл халкы базарны кире үз урынына кайтаруны сорап мөрәҗәгать итә. Базарның урынын алыштыру

сәүдә өчен уңайсызлыклар китереп чыгарган, күрәсең. Алар үтенечләрендә берничә сәбәпне күрсәтәләр: 1) зиратның якын булуын, базар вакытында кайбер кешеләрнең бернинди кирәксез зиратка керүләре, бу исә мөселманнарның дини хисләрен рәнҗетү; 2) базар урынының әйләндереп алынмавы һәм биналарның булмавы, кышкы бураннар һәм көчле яңгырлар вакытында аларда ышыкланырга мөмкинлек юклыгы, сәүдәне вакытыннан алда тәмамларга туры килүе һәм 3) базар урынында чүп-чар өелеп калуның санитар нормаларга туры килмәвен күрсәтәләр. Әмма, өяз управасы базарны кире үз урынына күчерергә рөхсәт бирми [16, 69д.–69д. кгз.].

1886 елда Иске Ашытта себер түләмәсе эпидемиясе кабынып китә, ул базардан сатып алган тире белән керә. Крестьяннар, сәүдәне дәвам итү өчен, эпидемия башлануын яшерәләр, нәтиҗәдә авылда булган 700 атның 200 е генә кала һәм авыру кешеләргә дә күчә башлый. Бу афәтне туктату өчен 7 атлы ветеринария сакчысы билгеләнә, шуларның 2 се Казанга, калганнары – Олы Мәңгәр, Олы Әтнә, Балтач, Иске Ашыт һәм Иске Тазлар авылларына. Алар үләт базларының торышын күзәтәләр. Базарга сатырга алып килгән мал-туарны тикшереп кертәләр. Шуңа да карамастан, базарда ялган язулы бик күп терлек сатыла. Хәтта җинаять өчен терлек белән сәүдә итүче 3 кеше хөкемгә тартыла [4, с.274].

Базар көннәрендә төрле эшсез халыкның күпләп килүе җинаятьчелек үсешенә, конфликтлар һәм тәртипсезлекләр барлыкка килүгә дә китергән. Авылда эчәргә яраклы биналар булу җирле халыкның, бигрәк тә яшьләрнең әхлакый халәтенә тискәре йогынты ясаган.

Иске Ашыт базары кабакларының хуҗалары Казан губернасы Мамадыш өязе крестьяны Бигинов Михаил һәм Арча шәһәре мещаны Барышев Алексей булган. Өлкән буын: «Кабаклар бары тик күңелсезлекләр генә китереп чыгара, чөнки безнең яшь буын аракының арзанлыгы аркасында эчүгә сабышты, төннәрен тәртипсезлекләр, сугышу, урлашу даими күзәтелеп тора», – дип хәбәр итә [6, 2–4 кгз.].

1903 елда мөселман руханилары старостасы Әбделҗан Абдуллатыпов инициативасы белән губерна хакимиятенә эчәргә яраклы биналарны ябу турында катгый үтенеч төзелә. Моны Казан өязенең 5 нче округ земство начальнигы хупласа да, Казан губернасы акциз җыемнары идарәсе тарафыннан шәраб сәүдәсен ябуга комачаулаучы нигезләр табылмый. Шулай да, иске ашытлыларның тырышлыгы аркасында шәраб кибете 1904 ел башында ябыла. Шуңа да карамастан, базар көннәрендә спиртлы эчемлекләрне сату дәвам ителә, бу авыл халкының рухи кыйммәтләренә, әхлагына һәм диненә тискәре йогынты ясый. Мәсәлән, 1915 елда «Кояш» газетасы: «Иске Ашыткa базарга килгән муллалар мунчага җыелалар һәм спиртлы эчемлекләр кулланалар», – дип язып чыга [1, с.91].

Казан арты авылларында базар-ярминкәләр авыл крестьяннары тормышында зур роль уйнаган дип әйтә алабыз. Кайбер тискәре күренешләр булса да, алар халык тормышына алай зур йогынты ясамаган. Һәрбер хуҗалык, продукция җитештереп, аны базарларда сатып, авыр тормышын җиңеләйтергә тырышкан. Шулай ук, алар арасында зур капитал туплап

баеп китүчеләр дә булган. Тарихта моны раслаучы фактлар аз түгел, араларында иганәчеләрнең мәчет-мәдрәсәләргә ярдәмнәре дә, хәйриячелек белән шөгельләнгәннәре дә билгеле.

**Чыганаклар һәм әдәбият**

1. *Багаутдинова Х.З.* Торговля и промыслы // История селений Ашитского джиена Заказанья: коллективная монография. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани, 2017. С.86–102.
2. Ново-Татарское кладбище Казани. Каталог-справочник памятных захоронений / автор-сост. А.И. Ногманов. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2021. 388 с.
3. Памятная книга Казанской губернии на 1863 год. Издание Казанского статистического комитета. Отдел IV. Сведения статистические. Казань, 1862. 222 с.
4. Постановления Казанского уездного земского собрания XXIII очередного с 15-го по 24-е октября 1887 года. Казань, 1888.
5. *Салихов Р.Р.* Заселение края // История селений Ашитского джиена Заказанья: коллективная монография. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани, 2017. С.8–25.
6. Татарстан Республикасы Дәүләт архивы (ТР ДА). 1 ф. 4 тасв. 1000 эш.
7. ТР ДА. 2 ф. 2 тасв. 8336 эш.
8. ТР ДА. 3 ф. 1 тасв. 2440 эш.
9. ТР ДА. 3 ф. 1 тасв. 2243 эш.
10. ТР ДА. 3 ф. 1 тасв. 4572 эш.
11. ТР ДА. 3 ф. 1 тасв. 9407 эш.
12. ТР ДА. 3 ф. 1 тасв. 13606 эш.
13. ТР ДА. 3 ф. 1 тасв. 13830 эш.
14. ТР ДА. 81 ф. 1 тасв. 32 эш.
15. ТР ДА. 81 ф. 2 тасв. 169 эш.
16. ТР ДА. 81 ф. 2 тасв. 511 эш.
17. ТР ДА. 119 ф. 1 тасв. 36 эш.
18. ТР ДА. 119 ф. 1 тасв. 166 эш.
19. ТР ДА. 119 ф. 1 тасв. 725 эш.
20. ТР ДА. 413 ф. 1 тасв. 533 эш.

## Из истории ярмарочной и базарной торговли в Заказанье (середина XIX – начало XX века)

***Х.З. Багаутдинова***
*Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ*
*Казань, Российская Федерация*

В статье рассматривается история базаров и ярмарок в населенных пунктах Заказанья в дореволюционный период. Проанализирован порядок открытия рынков и ярмарок в татарских и русских селах Казанского и Царевококшайского уездов. Изучена роль земства в развитии торговли, оценена роль торговли в жизни сельских

жителей. Даются краткие биографические сведения о крупных купцах, получивших наибольшую прибыль, их приказчиках. В ходе исследования выяснилось, что наибольший товарооборот был на базарах Арска и Большой Атни, самый низкий – в селах Русские Алаты и Большие Кургузи. С помощью сохранившихся в архиве данных удалось также установить национальность ряда купцов.

*Ключевые слова*: базары, ярмарки, Заказанье, торговый оборот, купцы, приказчики.

*Для цитирования:* Багаутдинова Х.З. Казан арты базарлары-ярминкәләре тарихыннан (XIX йөз уртасы – XX гасыр башы) // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. 2022. Т.12, №3. С. 20–28.

## From the history of fair and market trade in the Kazan region (mid XIX – early XX century)

***Kh.Z. Bagautdinova***
*Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*

The article deals with the history of bazaars and fairs in the settlements of the Kazan region in the pre-revolutionary period. The procedure for opening markets and fairs in the Tatar and Russian villages of the Kazan and Tsarevokokshay districts is analyzed. The activity of the zemstvo in the development of trade was studied, the role of trade in the life of rural residents was assessed. Brief biographical information is given about the major merchants who received the greatest profit, their clerks. In the course of the study, it turned out that the largest turnover was in the bazaars of Arsk and Big Atni, the lowest – in the villages Russkiye Alaty and Big Kurguzi. Also, with the help of the data preserved in the archive, it was possible to establish the nationality of a number of merchants.

*Keywords*: bazaars, fairs, Kazan region, trade turnover, merchants.

*For citation:* Bagautdinova Kh.Z. From the history of fair and market trade in the Kazan region (mid XIX – early XX century). From History and Culture of Peoples of the Middle Volga Region. 2022, vol. 12, no. 3, pp. 20–28. (In Tatar)

**Информация об авторе:**

**Багаутдинова Халида Зиннатовна** – научный сотрудник отдела истории Поволжья и Приуралья Института истории им. Ш.Марджани АН РТ (Казань, Российская Федерация); e-mail: halida12_61@mail.ru

**Баһаветдинова Халидә Зиннәт кызы** – ТР ФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Идел буе һәм Урал алды тарихы бүлеге фәнни хезмәткәре (Казан шәһәре, Россия Федерациясе).

**Bagautdinova Khalida Zinnatovna** – Researcher of the Department of History of the Volga and Cis-Urals Regions, Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (Kazan, Russian Federation).